**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.06.2019 № 445

**2019 елга муниципаль җир контроле өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын раслау турында**

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставына таянып

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елга муниципаль җир контроле өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 ел, 1 июнь, 445 номеры белән расланган карарына
1нче кушымта

# 2019 елга муниципаль җир контроле өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау Программасы

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Программа Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль җир контроле өлкәсендә федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауны оештыру максатларында эшләнгән.

1.2.Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә.

1.3. Программаның максатлары булып:

1.3.1. Мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерүне кертеп, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр (алга таба - контрольдә тотучы субъектлар) мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү;

1.3.2. Контрольдә тотылырга тиешле субъектларның намуслы тәртибенә мотивация булдыру;

1.3.3. Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян килү дәрәҗәсен киметү тора.

1.4. Программаның бурычлары булып:

1.4.1.Профилактик эшчәнлекне активлаштыру юлы белән мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау системасын ныгыту;

1.4.3. Юридик зат җитәкчеләренең һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукый аңын һәм хокукый культурасын күтәрү тора.

## 2. Профилактик чараларның План-графигы

| Тәртип саны | Чараның исеме | Үтәлү вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1. | Планлаштырылган һәм үткәрелгән тикшерүләр турында Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру юлы белән хәбәр итү | Даими рәвештә | «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ |
| 2. | «Татарстан Республикасы Нурлат | Атна саен, | «Татарстан |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе тарафыннан муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр оештыру һәм үткәрү, законнар таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча контрольдә тотылырга тиешле субъектларны кабул итү | сишәмбе (14.00 сәг-н) | Республикасы Нурлат муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ |
| 3. | Контрольдә тотылырга тиешле субъектларга җир законнары таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча телефон аша консультация бирү | Даими рәвештә | «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ |
| 4. | Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруның гомумиләштерелгән практикасын интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру | Елга бер тапкырдан да ким түгел | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 5. | Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларын кулланып аңлату эшләрен үткәрү буенча күрсәтмәләрне эшләү һәм бастырып чыгару юлы белән контрольдә тотылырга тиешле субъектларга хәбәр итү | Елга бер тапкырдан да ким түгел | «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырылган муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны контрольдә тоту буенча чаралар үткәргәндә үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актлар исемлеген актуаль хәлдә саклау | Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта | «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ |
| 7. | Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә урнаштырылган муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны контрольдә тоту чараларын уздырганда үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актлар текстларын актуаль хәлдә саклау | Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта | «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ |